**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№10541**
**31.10.2023**

«Шәҗәрә - нәсел агачы»
шәһәр конкурсын оештыру һәм
үткәрү турында

Башкарма комитетның 2022 елның 19 октябрендәге 5650 номерлы карары белән расланган 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын үтәү йөзеннән, гаилә традицияләрен пропагандалау һәм популярлаштыру, гаиләләрдә буыннар бәйләнешен ныгыту максатларында

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә «Шәҗәрә - нәсел агачы» шәһәр конкурсын оештыруны һәм Яр Чаллы шәһәренең «Эврика» шәһәр мәдәният үзәге» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесендә 2023 елның 21 ноябрендә үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) «Шәҗәрә - нәсел агачы» шәһәр конкурсын үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) «Шәҗәрә - нәсел агачы» шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауны 2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 0801 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 10 000 (ун мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 31 октябрендәге
10541 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Шәҗәрә - нәсел агачы»
шәһәр конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә «Шәҗәрә - нәсел агачы» («Моя родословная») конкурсының (алга таба - конкурс) максатларын, бурычларын һәм үткәрү тәртибен, эчтәлеген һәм катнашучыларга карата таләпләрне билгели.

2. Конкурсның оештыручылары: Башкарма комитетның мәдәният идарәсе ярдәме белән, Яр Чаллы шәһәренең «Эврика» шәһәр мәдәният үзәге» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе.

2 бүлек. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

3. Конкурсны үткәрүнең төп максатлары һәм бурычлары булып тора:
- буыннар дәвамлылыгын саклау, гаилә һәм гаилә-туганлык бәйләнешләрен ныгыту;
- үз нәселеңнең, халкыңның, туган ягыңның тарихын өйрәнү;
- Татарстан Республикасы халыкларының милли традицияләрен, гореф-гадәтләрен торгызу;
-гаилә традицияләрен һәм кыйммәтләрен пропагандалау һәм популярлаштыру.

3 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

4. Конкурс 2023 елның 21 ноябрендә В. Гостев урамы, 29 йорт адресы буенча үтәчәк. Конкурсны үткәрү тәртибе, сроклары һәм үткәрү шартлары турында мәгълүмат рәсми сайтта http://evrika-chelny.ru/, https://vk.com/club102744487.

5. Конкурста нинди милләттә һәм диндә булуына карамастан, гаилә-нәсел төркеменең берничә буын катнашучыларын берләштерә торган гаилә коллективлары (гаилә-туганлык төркемнәре) яшь буенча чикләүләрсез катнаша.

6. Конкурста катнашу өчен гариза бирүчеләр заяканы 2023 елның 7 ноябреннән 18 ноябренә кадәр кәгазьдә В. Гостев урамы, 29 йорт адресы буенча, электрон рәвештә evtika.konkurs@mail.ru почтасына җибәрәләр һәм түбәндәге документларны тапшыралар:
- конкурста катнашуга анкета-заявка (әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымта);
- гаилә-туганлык төркеменең нәсел агачы;
- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымта).

7. Конкурста катнашу бушлай.

8. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

Оештыру комитеты:
1) конкурсны үткәрүне турыдан-туры тәэмин итә;
2) конкурсның жюри составын формалаштыра;

3) конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча эшләрне координацияләүне гамәлгә ашыра;

4) оештыру мәсьәләләрен хәл итә.

9. Конкурсның жюрие:

1) конкурста катнашучылар тарафыннан биремнәрне һәм башка төр сынауларны үтәүне тикшерә һәм бәяли;

2) конкурсның җиңүчеләрен билгели.

4 бүлек. Конкурс номинацияләре

10. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

- «Безнең династия» (һөнәр династиясен, аның җәмгыять тормышында һәм гаиләдәге ролен тасвирлау);

- «Гаилә ядкаре». Катнашучылар гаилә өчен кадерле булган предмет турында хикәя (эссе) тапшыралар. Бу кием, савыт-саба, бизәнү әйберсе, көнкүреш предметы, фотографияләр, киноматериаллар һ.б. булырга мөмкин;

- «Минем нәсел агачы». Катнашучылар гаиләнең нәсел агачы турында тикшеренү эшен – бер гаилә үрнәгендә нәсел агачын һәм гаиләнең бер әгъзасы турында хикәя (эссе) тәкъдим итәләр. Тикшерелә торган буыннар биштән ким булмаска тиеш.

5 бүлек. Эшләрне рәсмиләштерүгә карата таләпләр.

11. Конкурста катнашу өчен гаилә династияләрен сурәтләгән нәсел агачы (шәҗәрә), реликвияләр һәм коллекцияләр турында материаллар, гаилә коллективы тормышыннан кызыклы фактлар (гаилә риваятьләре), өстәмә материаллар (фотографияләр, гаилә ядкарьләре, мультимедиа материаллар һ.б.) тапшырырга кирәк, алар тәкъдим ителгән шәҗәрәгә тестлы нигезләмә белән (текст форматы А4, шрифт Times New Roman, шрифт үлчәме - 14), альбом, стенд, панно, баннер-коллаж рәвешендә ясалырга тиеш.

6 бүлек. Бәяләү критерийлары

12. Конкурста катнашучыларның эшләре жюри тарафыннан 10 баллы система буенча бәяләү критерийлары нигезендә бәяләнә. Жюри эшенең нәтиҗәсе булып тутырылган һәм имзаланган, баллар куелган индивидуаль эксперт битләре тора. Алынган баллардан чыгып, уртача арифметик йомгаклау бәясе формалаштырыла. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

13. Конкурс эшен бәяләү критерийлары:

1) китерелгән тарихи фактларны бәян итүнең тарихи дөреслеге, төгәллеге һәм намуслылыгы;

2) гаилә кыйммәтләрен пропагандалау дәрәҗәсе, традицион гаилә кыйммәтләренә бирелгәнлек;

3) күмәк хезмәткә мотивация, ата-аналарның һәм балаларның төрле гаилә эшләрендә катнашу активлыгы һәм дәрәҗәсе;

4) файдаланыла торган тарихи чыганакларның төрлелеге (документлар, хатлар, гаилә риваятьләре һ.б.);

5) үз гаиләсенең килеп чыгышы һәм милли тамырлары турындагы белемнәрнең тирәнлеге;

6) нәсел вәкилләренең тарихта, регион һәм ил тормышында роле турында белемнәрнең тирәнлеге;

7) үз фамилиясенең килеп чыгышы турында мәгълүматларның нигезлелеге һәм дөреслеге;

8) гаилә тарихын өйрәнү мәсьәләләрендә гаиләнең иҗади якын килүе һәм социаль активлыгы;

9) эшнең сәнгати өстенлекләре (әдәби тел, бәян итүнең образлылыгы, рәсем ясау осталыгы);

10) кушымталарда конкурс эшенең төп эчтәлеген чагылдыру дәрәҗәсе.

7 бүлек. Конкурсның җиңүчеләре һәм нәтиҗәләре

14. Конкурс нәтиҗәләре буенча һәр номинациядә җиңүчеләр билгеләнә, алар I, II һәм III дәрәҗә дипломнар, шулай ук призлар белән бүләкләнә. Барлык катнашучылар да конкурста катнашучы дипломы ала.

15. Конкурс нәтиҗәләре беркетмә имзаланганнан соң 3 көннән дә соңга калмыйча «Эврика» шәһәр мәдәният үзәге» МАМУ сайтында «https://vk.com/club10274487 урнаштырылачак.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

«Шәҗәрә - нәсел агачы»
шәһәр конкурсын үткәрү
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

«Шәҗәрә - нәсел агачы» («Моя родословная»)
шәһәр конкурсында катнашуга заявка

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Катнашучының Ф.И.А.и., туган көне | |
| 2. | Яшен һәм катнашучыга карата туганлык мөнәсәбәтен күрсәтеп, гаиләдән катнашучыларның (булса) Ф.И.А.и. | |
| 3. | Гаилә турында кыскача мәгълүмат | |
| 4. | Элемтә өчен мәгълүмат (телефон, e-mail) | |
| 5. | Тәкъдим ителгән эшнең номинациясе | |

_______________ Дата, имза

«Шәҗәрә - нәсел агачы»
шәһәр конкурсын үткәрү
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин______________________________________________________________________,
_
теркәлү адресым:____________________________________________________,
шәхесне таныклаучы документ:___________________________________________
(күрсәтелгән документны бирү датасы һәм аны биргән орган турында мәгълүматлар), Россия Федерациясенең «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә «Шәҗәрә - нәсел агачы» («Моя родословная») конкурсын оештыручыларга, конкурс нигезләмәсе белән билгеләнгән таләпләргә туры килүне тикшерү максатында, аларны эшкәртү күрсәтелгән мәгълүматларның конфиденциальлеген саклау турында бурычларны үз өстенә алган вәкаләтле затлар тарафыннан гамәлгә ашырылу шарты белән, минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыгымны раслыйм. Минем шәхси мәгълүматларымны башка затларга тапшыру яки аларны башкача ачып салу минем язма ризалыгым белән генә гамәлгә ашырылырга мөмкин. Мин тиешле язма документ төзү юлы белән ризалыгымны кире алу хокукын үземдә калдырам, әлеге документ конкурсны оештыручылар адресына минем тарафтан почта буенча белдерү белән заказлы хат итеп җибәрелергә яисә конкурсның вәкаләтле вәкиленә расписка белән шәхсән тапшырылырга мөмкин.

Әлеге ризалыкны бирдем: «___» _____________ 2023 ел.

Имза: _______________/__________/